# Чаллыда – әдәби вакыйга

**Нәкъ бер ай элек, 2024 елның 17 декабрендә, Чаллыда Әдәбият көне узды. Әлеге тантана күренекле әдип, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш, С.Сөләйманова, Ш.Галиев, И.Юзеев исемендәге әдәби премияләр лауреаты Рәшит Бәшәрнең 75 яшьлек юбилее уңаеннан, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге башлангычы белән, Татарстан Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге, Чаллы шәһәре хакимияте һәм А.Гыйләҗев исемендәге Чаллы Татар дәүләт драма театры тарафыннан оештырылды.**




Тантанага Казаннан мәртәбәле әдипләр килгән иде, аларга Чаллыда яшәүче танылган каләм ияләре кушылды. Зур әдәбият бәйрәменә эверелгән чара шәһәребезнең төрле мәктәпләрендә укучылар белән очрашулардан башланып китте.

Язучылар төркемнәргә бүленде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җитәкчелегендәге әдәби десант (шагыйрьләр Факил Сафин һәм Рәзинә Мөхияр) 58 нче гомуми белем бирү мәктәбенә юл алды. ГЭС бистәсендәге 12нче гомуми белем бирү мәктәбендә шагыйрьләр Газинур Морат, Рифә Рахман, Айрат Суфиянов очрашу үткәрде.

Күршедәге 3 нче урта мәктәптә Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, шагыйрәләр Йолдыз Шәрәпова һәм Лилия Гыйбадуллина мәйдан тотты.

18 мәктәптә шагыйрь Илфак Ибраһимов, язучы-драматурглар Айгөл Әхмәтгалиева, Булат Сәлахов, Актанышта яшәп иҗат итүче каләмдәшебез – Башкортстан Язучылар берлеге әгъзасы Габдулла Вафин очрашу үткәрде.

79 лицей-интернатта, шагыйрь-прозаиклар Галимҗан Гыйльманов, Рафис Корбан, Әлфия Ситдыйкова катнашында кызыклы, мавыктыргыч чара узды.

Рәшит Бәшәрнең юбилеена багышланган төп тантана А.Гыйләҗев исемендәге Чаллы Татар дәүләт драма театрының зур залында дәвам итте. Юбилярның тормышына һәм иҗатына багышланган театраль тамаша һәркемнең күңеленә хуш килерлек иде. Иң төп үзенчәлек – сәхнәне, театр артистлары белән бергә, 82 нче «Көнбагышкай» балалар бакчасы сабыйлары, 2, 29, 54 нче гимназияләр һәм «Адымнар-Чаллы» полилингваль мәктәбе, шулай ук Г.Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат укучылары да тотты.

Үзешчән композитор буларак та танылу алган, республикакүләм бәйгеләр җиңүчесе Факил Сафин каләмдәше Р.Бәшәр сүзләренә байтак җырлар язган икән, бу кичәдә, әлбәттә, алар да яңгырады. Җырчы Рим Кәримов, «Болгарым» җырын башкарып, кичәнең дәрәҗәсен тагын да күтәреп җибәрде.

Театрда җырчы артистлар булуы сөендерә: Марсель Мосавиров – «Татар кызы», Руслан Әюпов «Туган нигез» җырларын зур осталык белән башкарды. 13 нче сәнгать мәктәбеннән Лиана Әнәсова һәм Дарина Хлыстова башкаруындагы «Туган җир», «Сандугачлы бакча» җырларын, «Миләш», һәм «Гөлчәчәк» вокаль төркемнәре башкарган «Сабан туе» җырын тамашачылар тын да алмый тыңлады. «Изумрудинка» бию коллективының (җитәкчесе Ю.Корбанова) чыгышы да бизәк өстенә бизәк булды. Шулай ук «Агадир» цирк студиясе (җитәкчесе И.Чувашова), «Яр Чаллы» бал биюләре студиясе коллективы (җитәкчесе М.Сойка), «Энергетик» мәдәният сарае каршында эшләүче «Йолдыз» балалар җыр студиясе (җитәкчесе Г.Гомәрова) чыгышлары бик күркәм булды.

Юбилярны шәһәр башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Винер Харисов, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, ТР Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Язучыларның Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, Кукмара якташлыгы җәмгыяте җитәкчесе Фирдәвис Гаянов һ.б. котлады.

Әдәби музыкаль кичәнең сценарий авторы – Валентина Ибраһимова, режиссеры А.Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов иде.

**Әлфия СИТДЫЙКОВА.**